| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2021 Казан ш. № 323-60/тэ-2021

Кулланучыларга «Теплокоминвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 № 221-28/тэ-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2022-2025 елларга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2022-2025 елларга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Теплокоминвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү турында» 11.11.2020 № 221-28/тэ-2020 карарының 1 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 № 221-28/тэ-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.11.2021 № 323-60/тэ-2021 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

# 2021-2025 елларга «Теплокоминвест» ҖЧҖ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланган пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Биектау муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Теплокоминвест» ҖЧҖ* | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1682,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1723,40 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1723,40 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1792,71 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 1792,71 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1831,05 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1831,05 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 1883,75 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 1883,75 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 1919,21 | - | - | - | - | - |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге